СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.03.2019 Баулы шәһәре № 201

Баулы муниципаль районы
Советының 2018 елның 3
июлендә кабул ителгән 161нче
номерлы «Хезмәт (вазыйфаи)
тәртибенә карата таләпләрне
үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын
җайга салу буенча комиссия турында
Нигезләмәне раслау хакында»гы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092нче номерлы Указы нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендә кабул ителгән 161нче номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына, 3.2.6 пунктын өстәп, түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3.2.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3 һәм 3.2.4 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләр үз эченә алырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә белдерүләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) мөрәҗәгатьләр нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр яисә белдерүләрне, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.10.1, 3.10.3, 3.11.1 пунктларына ярашлы рәвештә карарларның берсен кабул итү өчен рекомендацияләрне алдан карау нәтиҗәсендә ясалган дәлилләнгән нәтиҗә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин